КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 22 май г.Казань № б-1047

Торышы канәгатьләнерлек булмаган объектларга карата Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның нәтиҗәле хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында:

1. Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 30 мартындагы Пр-616 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 21 пунктындагы «а» пунктчасын үтәү буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Бу боерыкка теркәлгән Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 30 мартындагы Пр-616 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 21 пунктындагы «а» пунктчасын үтәү буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 22 май, б-1047 нче
боерыгы белән расланды

Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 30 мартындагы
Пр-616 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 21 пунктындагы «а» пунктчасын
үтәү буенча ведомствоара эшче төркем турында
нигезләмә

1. Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 30 мартындагы Пр-616 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 21 пунктындагы «а» пунктчасын үтәү буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – ведомствоара эшче төркем) – ул торышы канәгатьләнерлек булмаган объектларга карата Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) (алга таба – мәдәни мирас объектлары) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның нәтиҗәле хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында, шулай ук мондый мәдәни мирас объектларының санын киметү һәм аларны саклап калу проектларына инвестицияләр җәлеп итү максатларында төзелгән координация органы.

2. Ведомствоара эшче төркем үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Ведомствоара эшче төркемнең төп бурычлары:

а) мәдәни мирас объектларын хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

б) түбәндәгеләргә юнәлдерелгән дәүләт сәясәте чараларын эшләү:

инвесторлар өчен мәдәни мирас объектларын саклап калу проектларының икътисадый җәлеп итүчәнлеген тәэмин итә торган инвестиция модельләрен үстерүгә;

хосусый инвестицияләр күләмен арттыру максатларында мәдәни мирас объектларын саклап калу һәм алардан файдалану проектларына инвесторларның җәлеп ителүен стимуллаштыруга;

в) мәдәни мирас объектларын саклап калу проектларын финанслауның гамәлдәге инструментларын үстерү һәм яңаларын эшләү, шул исәптән бу өлкәдә концессия килешүләре, дәүләти-хосусый (муниципаль-хосусый) партнерлык турында килешүләр төзү тәҗрибәсен кертү юлы белән;

г) түбәндәгеләргә кагылышлы мәсьәләләрне карап тикшерү һәм тәкъдимнәр әзерләү:

гражданнарның мәдәни мирас объектларыннан файдалана алуын тәэмин итү, аларның туристлык һәм мәдәни потенциалын үстерүгә;

мәдәни мирас объектларын хуҗалык әйләнешенә кертүне дә кертеп, мондый чараларны гамәлгә ашыруның барлык этапларында мәдәни мирас объектларын

саклап калу чараларында катнашучы инвесторлар булышлык күрсәтеп тору механизмын булдыруга;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәдәни мирас объектларына инвестицияләр кертүдә ярдәм күрсәтүгә;

хуҗалык әйләнешенә кертелгәндә мәдәни мирас объектларының сакланышын тәэмин итүгә;

д) торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларын хуҗалык әйләнешенә кертү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисенә тәкъдимнәр әзерләү;

е) торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларын хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисенә актуаль мәгълүмат кертү;

ж) мәдәни мирас объектларын саклап калуга бәйле башка мәсьәләләрне карап тикшерү.

4. Үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итү өчен ведомствоара эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

а) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка дәүләт органнарыннан, иҗтимагый, фәнни, финанс һәм башка оешмалардан ведомствоара эшче төркем компетенциясенә карый торган мәсьәләләр буенча тиешле материалларны һәм мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

б) үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, башка дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, шулай ук иҗтимагый, фәнни, финанс һәм башка оешмаларның вазыйфаи затларын чакырырга;

в) экспертлар сыйфатында галимнәр һәм белгечләр җәлеп итәргә;

г) ведомствоара эшче төркем компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый, фәнни, финанс һәм башка оешмалар эшчәнлеген координацияләүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар кабул итәргә һәм тәкъдимнәр эшләргә.

5. Ведомствоара эшче төркем утырышлары ведомствоара эшче төркем җитәкчесе карары буенча уздырыла.

6. Эшче төркем утырышларын эшче төркем җитәкчесе яки аның кушуы буенча эшче төркем җитәкчесе урынбасары үткәрә.

7. Ведомствоара эшче төркем җитәкчесе:

а) ведомствоара эшче төркем эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгели;

б) ведомствоара эшче төркем утырышларының көн тәртибен раслый;

в) ведомствоара эшче төркем утырышларын алып бара;

г) үзенә йөкләнгән бурычларны хәл итүгә бәйле мәсьәләләр буенча ведомствоара эшче төркем әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

д) Татарстан Республикасы Рәисенә ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге нәтиҗәләре турында докладлар кертә.

8. Ведомствоара эшче төркем әгъзалары:

а) ведомствоара эшче төркем утырышларының көн тәртибе буенча тәкъдимнәр

кертә;

б) ведомствоара эшче төркем утырышларына материаллар, шулай ук ведомствоара эшче төркем карарлары проектларын әзерләүдә катнаша;

в) утырышта булмаган очракта, ведомствоара эшче төркем утырышында карап тикшерүгә билгеләнгән мәсьәләләр буенча үз фикерләрен утырыш башланырга бер эш көненнән дә соңга калмыйча язма рәвештә кертергә хокуклы.

9. Ведомствоара эшче төркем секретаре:

а) ведомствоара эшче төркем әгъзаларына ведомствоара эшче төркем утырышын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында һәм утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр турында хәбәр итә;

б) ведомствоара эшче төркем утырышларының көн тәртибе проектларын һәм аның карарлары проектларын әзерли, ведомствоара эшче төркем утырышларына кирәкле документлар һәм аналитик материаллар әзерләүне оештыра;

в) ведомствоара эшче төркем утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә;

г) ведомствоара эшче төркем эшчәнлеге нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Рәисенә доклад проектын әзерли һәм ведомствоара эшче төркем җитәкчесенә карауга кертә.

10. Тавыш биргәндә ведомствоара эшче төркемнең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Ведомствоара эшче төркем карарлары, ведомствоара эшче төркемнең катнашмаган әгъзалары тарафыннан билгеләнгән срок эчендә бирелгән язма фикерләрне исәпкә алып, утырышта катнашучы ведомствоара эшче төркем әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм ведомствоара эшче төркем утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Тавыш биргәндә тавышлар саны тигез булганда, ведомствоара эшче төркем утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

11. Ведомствоара эшче төркем карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа ведомствоара эшче төркем утырышында рәислек итүче тарафыннан кул куела. Ведомствоара эшче төркем утырышы беркетмәсе (беркетмәдән өземтәләр) күчермәләре ведомствоара эшче төркем әгъзаларына, шулай ук Татарстан Республикасы субъектларының кызыксынучы дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына һәм оешмаларына, җирле үзидарә органнарына җибәрелә.

12. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә ведомствоара эшче төркем карарларын үтәүгә җәлеп ителә.

13. Ведомствоара эшче төркем карарларын үтәү өчен Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәләре (актлары) проектлары әзерләнергә мөмкин.

________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 22 май, б-1047 нче
боерыгы белән расланды

Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 30 мартындагы
Пр-616 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 21 пунктындагы «а» пунктчасын үтәү
буенча ведомствоара эшче төркем
составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, ведомствоара эшче төркем җитәкчесе |
| Гущин Иван Николаевич | Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе, ведомствоара эшче төркем җитәкчесе урынбасары |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, ведомствоара эшче төркем секретаре |

Ведомствоара эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Арсланов Азат Мөхәммәтгали улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы урынбасары |
| Беляев Радмир Илдар улы | Татарстан Республикасының Түбән Кама муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Галиев Артур Ирек улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары |
| Җиһаншин Айрат Габделхак улы | Татарстан Республикасының Апас муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Димитриев Сергей Димитриевич | Татарстан Республикасының Кукмара муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Иванов Дмитрий Алексеевич | Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Исланов Роман Леонидович | Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Ишкиниев Дамир Азат улы | Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Кәримов Разиф Гали улы | Татарстан Республикасының Зәй муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Кудряшев Владимир Николаевич | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Нуриев Рөстәм Мидхәт улы | Татарстан Республикасының Алабуга муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Нутфуллин Рамил Рәшит улы | Татарстан Республикасының Балтач муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Сафиуллов Рәмис Хатыйп улы | Татарстан Республикасының Тәтеш муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Фәттахов Дамир Илдус улы | Татарстан Республикасының Бөгелмә муниципаль районы башлыгы (килешү буенча) |
| Хисамиев Рөстәм Шаһит улы | Татарстан Республикасының Әтнә муниципаль районы башлыгы (килешү буенча). |